КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 август г.Казань № 684

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпо-зиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпо-зиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нче; 2017 ел, 21 март, 167 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1113 нче, 2019 ел, 20 сентябрь, 861 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр,

киңәшмәләр, симпо-зиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү процессында тормый, аңарга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылып тормый.»;;

6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы җитәкчесе тарафыннан имзаланган, субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, субсидия алучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмауны раслый торган гарантия хаты.»;

17 пунктта:

өченче абзацта «файдалану турында хисап» сүзләрен «бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Килешүдә субсидия бирүнең түбәндәге нәтиҗәләре билгеләнә:

субсидия бирү турында килешүдә каралган эшләрнең срокларын һәм күләмнәрен башкаручы тарафыннан бозулар булмау;

үткәрергә субсидия бирелә торган чарада катнашучылар тарафыннан шикаятьләрнең булмавы.»;

19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия алучылар Министрлыкка субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыралар.»;

20 пунктка «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәү турында» сүзләрен өстәргә;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымта өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференция-ләр, киңәшмәләр, симпо-зиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субси-дияләр бирү тәртибенә кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның ______ карары белән расланда)

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
ХИСАП

20__ елның «__» ________ торышы буенча

Юридик затның исеме: ________________________________________

Даимилек: ________________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә атамасы | Проект-ның (чара) исеме | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч-нең план-дагы мәгънәсе | Нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткечнең хисап датасына ирешелгән мәгънәсе | Күрсәткеч-нең пландагы мәгънәсе үтәлеше проценты | Күрсәт-кечнең пландагы мәгънә-сеннән тайпылу-ның сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | код | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Юридик зат җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ______________________________ ________________ _____________________
(вазыйфасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Башкаручы ___________________________________ ___________________________ _______________
(вазыйфасы) (Ф.И.Ә.и. (соңгысы – булганда) (телефон)

«____» ________ 20__ ел

_____________________________________